**Татарстан РеспубликасыЗәймуниципальрайонының**
**Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**№ 179** **24.07.2025 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 21 декабрендә № 132номерлыЗәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Терлекләр белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 октябрендәге № 498-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Уставына таянып,Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 21 декабрендә № 132номерлы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 169 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«169.Хайваннар белән эш итү өлкәсендәге мөнәсәбәтләр "Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законы, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, шулай ук алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән җайга салына.»;

1.2. 170 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«170. Авыл хуҗалыгы хайваннарын һәм кошларын чыгару бары тик җирлек Башкарма комитетының норматив-хокукый акты белән билгеләнә торган бу урыннарда гына рөхсәт ителә.»;

1.3. 171 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«171. Әйләндереп алынмаган көтүлекләрдә көтүлек бәйдә якиавыл хуҗалыгы хайваннары (кошлары) хуҗалары якихуҗалар яки вәкаләтле затлар белән авыл хуҗалыгы хайваннарын (кошларны) көтү буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешүләр төзегән затлар күзәтүе астында башкарыла.»;

1.4. 172 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«172.Хайваннарны (кошларны) күзәтүсез калдыру, урамнарда һәм бу максатлар өчен билгеләнмәгән башка урыннарда көтү, чәчәклекләрне һәм культуралар чәчүлекләрен таптату тыела.»;

1.5 173-189 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **М. Х. Туктаров**